РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
БУИНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
ГЛАВА
МОКРОСАВАЛЕЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
МӨКЕРЛЕ
АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

10 июль 2024 ел № 7

Җир кишәрлеген шартлы рәвештә файдалануга рөхсәт бирү мәсьәләсе буенча гавами тыңлаулар билгеләү турында

«Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә вәкаләтләрне яңадан бүлү турында» 2023 елның 23 декабрендәге 131-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2023 елның 29 декабрендәге 1743 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарының 4.2 пункты, шулай ук РФ ГК 39 статьясының 4 өлеше нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. 2024 елның 22 июленә Татарстан Республикасы, Буа муниципаль районы, Мөкерле авыл җирлеге, Мөкерле авылы, Совет урамы, «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы «Мөкерле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренең индивидуаль торак төзелеше зонасында» элемтә хезмәтләре күрсәтү (код 3.2.3) " 8А җир кишәрлеге адресы буенча урнашкан 197 кв. м мәйданлы 16:14:110401:759 кадастр номерлы җир кишәрлеген шартлы рәвештә рөхсәт ителгән файдалану төренә рөхсәт бирү мәсьәләсе буенча гавами тыңлаулар уздыруны билгеләргә.

2. Җир кишәрлеген шартлы рәвештә файдалануга рөхсәт бирү мәсьәләсе буенча гавами тыңлаулар уздырырга:

- Татарстан Республикасы, Буа районы, Мөкерле авылы, Яшьләр урамы, 9:00 сәгатьтә авыл мәдәният йорты бинасында;

3. Гавами тыңлауларны Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Мөкерле авыл җирлеге Советының 2007 елның 21 маендагы 2-20 номерлы карары белән расланган Буа муниципаль районы Мөкерле авыл җирлегенең гавами тыңлауларын оештыру һәм үткәрү турындагы нигезләмәдә билгеләнгән тәртип буенча, шулай ук РФ ГК 5.1 һәм 39 статьяларында билгеләнгән таләпләргә ярашлы рәвештә үткәрергә;

4. Фикер алышу мәсьәләләре буенча язма рәвештә тәкъдимнәр һәм искәрмәләр, шулай ук гавами тыңлауларда катнашу өчен гаризалар түбәндәге адрес буенча бирелергә мөмкин: ТР, Буа муниципаль районы, Мөкерле авылы, Яшьләр урамы,49 йорт (эш көннәрендә - 8.00 дән 17.00 гә кадәр). Чыгыш ясау хокукы белән гавами тыңлауларда катнашу өчен гаризалар бирү вакыты 2024 елның 15 июле. Тәкъдимнәр һәм искәрмәләр шулай ук гавами тыңлауларда катнашучылар җыелышы вакытында язма яки телдән бирелергә мөмкин.

5. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Мөкерле авыл җирлеге башкарма комитетына:

- әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru, шулай ук Буа муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга: http://buinsk.tatarstan.ru.

- гавами тыңлауларга әзерлекне, гавами тыңлауларда катнашучыларның җыелышларын билгеләнгән срокларда үткәрүне тәэмин итәргә;

- гавами тыңлаулар беркетмәсен әзерләүне һәм рәсмиләштерүне тәэмин итәргә;

- гавами тыңлаулар нәтиҗәләре буенча Буа муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә бастырып чыгарырга: http://buinsk.tatarstan.ru.

6. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккан көннән законлы көченә керә.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Буа муниципаль районы Мөкерле
авыл җирлеге башлыгы _______________ С.Н. Тюплина